**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» апрель, 2025 ел № 168-п

2025 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Торак кодексы, 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителергә тиешле мөлкәт хакын «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы»ның 2025 елның 14 февралендәге 73 номерлы хаты нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 3 688 129,5 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 4 693 983,00 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 6 035 121,00 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 8 046 828,00 сум

1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 10 058 535,00 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 12 070 242,00сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 14 081 949,00 сум

1.2. 1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 48 324,55 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 30 751,98 сум

1.2.3. Өч кеше һәм аннан да күбрәк гаилә өчен - 26 358,84 сум

2. Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә

Питрәч муниципаль районы наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән максималь күләмнәрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе — И.Р. Дәүләтханов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605387